КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 ноябрь

г.Казань

№ 1050

Порттагы гидротехник корылмаларны (шул исәптән причалларны), күчереп төяү комплексларын һәм елга портында урнашкан башка мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар белән каралган йөкләмәләрне үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 303 статьясы, «Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Порттагы гидротехник корылмаларны (шул исәптән причалларны), күчереп төяү комплексларын һәм елга портында урнашкан башка мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар белән каралган йөкләмәләрне үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче, 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче, 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче, 2006 ел, 1 март, 87 нче, 2006 ел, 21 апрель, 198 нче, 2006 ел, 9 июнь, 293 нче, 2007 ел, 18 май, 196 нчы, 2008 ел, 15 июль, 509 нчы, 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы, 2009 ел, 17 август, 551 нче, 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы, 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче, 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче, 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче, 2012 ел, 22 август, 726 нчы, 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы, 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы, 2013 ел, 7 март, 152 нче, 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы, 2013 ел, 10 август,

558 нче, 2014 ел, 21 апрель, 261 нче, 2015 ел, 1 июнь, 397 нче, 2016 ел, 10 октябрь, 733 нче, 2016 ел, 13 декабрь, 925 нче, 2017 ел, 6 март, 127 нче, 2017 ел, 26 май, 309 нчы, 2017 ел, 14 ноябрь, 867 нче, 2018 ел, 4 июль, 545 нче, 2018 ел, 24 июль, 586 нчы, 2018 ел, 10 декабрь, 1107 нче, 2018 ел, 14 декабрь, 1135 нче, 2019 ел, 16 апрель, 301 нче, 2019 ел, 21 май, 416 нчы, 2019 ел, 15 июнь, 493 нче, 2019 ел, 13 июль, 576 нчы, 2019 ел, 12 октябрь, 907 нче, 2020 ел, 10 февраль, 83 нче, 2020 ел, 18 май, 400 нче, 2020 ел, 28 май, 436 нчы, 2020 ел, 13 июль, 577 нче, 2020 ел, 10 октябрь, 917 нче, 2020 ел, 27 октябрь, 962 нче, 2020 ел, 2 декабрь, 1087 нче, 2021 ел, 31 август, 790 нчы, 2022 ел, 1 апрель, 306 нчы, 2022 ел, 16 июнь, 567 нче, 2022 ел, 22 декабрь, 1395 нче, 2023 ел, 10 гыйнвар, 2 нче, 2023 ел, 6 март, 221 нче, 2023 ел, 2 июнь, 676 нчы, 2023 ел, 10 октябрь, 1292 нче, 2023 ел, 29 декабрь, 1721 нче, 2024 ел, 16 февраль, 86 нчы, 2024 ел, 12 апрель, 251 нче, 2024 ел, 1 июль, 481 нче, 2024 ел, 2 июль, 493 нче, 2024 ел, 9 август, 639 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«порттагы гидротехник корылмаларны (шул исәптән причалларны), күчереп төяү комплексларын һәм елга портында урнашкан башка мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар белән каралган елга портының канәгатьләнерлек булмаган халәттәге мондый объектларын сату-алу шартнамәсендә билгеләнгән биш елдан артмаган срокта тиешле хәлгә китерү буенча йөкләмәләрне үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыра.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы, 2006 ел, 19 июнь, 312 нче, 2010 ел, 31 май, 419 нчы, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы, 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы, 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы, 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы, 2013 ел, 19 март, 185 нче, 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче, 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче, 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы, 2016 ел, 19 март, 150 нче, 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы, 2017 ел, 3 февраль, 58 нче, 2017 ел, 20 апрель, 232 нче, 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче, 2018 ел, 22 март, 161 нче, 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы, 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче, 2019 ел, 16 март, 185 нче, 2019 ел, 22 июль, 613 нче, 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы, 2020 ел, 11 июль, 575 нче, 2020 ел, 19 август, 710 нчы, 2021 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы, 2021 ел, 18 июнь, 476 нчы, 2021 ел, 6 декабрь, 1168 нче, 2022 ел, 22 апрель, 389 нчы, 2022 ел, 1 июнь, 511 нче, 2022 ел, 18 август, 852 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 946 нчы, 2022 ел, 1 ноябрь, 1165 нче, 2022 ел, 5 декабрь, 1288 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1485 нче, 2023 ел, 12 апрель, 451 нче, 2023 ел, 9 июнь, 704 нче, 2023 ел, 2 август, 936 нчы, 2023 ел, 31 август, 1058 нче, 2024 ел, 20 май, 339 нчы, 2024 ел, 24 июнь, 453 нче, 2024 ел, 4 июль, 500 нче, 2024 ел, 30 октябрь, 942 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле 3.3 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«порттагы гидротехник корылмаларны (шул исәптән причалларны), күчереп төяү комплексларын һәм елга портында урнашкан башка мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар белән каралган елга портының мондый объектларын

пассажирларга һәм судноларга хезмәт күрсәтү, төяү, бушату, кабул итү, йөкләр саклау һәм тапшыру, транспортның башка төрләре белән хезмәттәшлек итү максатларында файдалану буенча йөкләмәләрне үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыра.».

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин